Татар гомуми белем бирү оешмаларында укучылар өчен татар әдәбиятыннан олимпиада сораулары
(мәктәп туры, 2017-2018 уку елы). 8 нче сыйныф

Үткәрү вакыты – 60 минут.
Максималь балл – 41.

I. Теоретик биремнәр. (8 балл)

1. Мәгърифәтчелек әсәрләрендә төп конфликт кемнәр арасында барлыкка килә һәм ничек тәмамлана? (5 балл)

2. Түбәндә аталган әдипләрнең кайсылары XX йөз башында актив иҗат эше белән шөгыльләнә. (3 балл)

А) Мөхәммәдъяр
Б) Г.Тукай
В) К.Насыйри
Г) Ш.Камал
Д) Н.Думави

II. Әдәби әсәргә кагылышлы биремнәр. (18 балл)

1. Мөхәммәдъярның “Нәсыйхәт” шигырендә нинди символик образларга мөрәҗәгать ителә, санап чыгыгыз. (3 балл)

2. Мөхәммәдъярның “Нәсыйхәт” шигырендә җиткерелгән төп идеяне ачыклап языгыз, укучыга нинди фикер әйтелә? (5 балл)

3. Мөхәммәдъярның “Нәсыйхәт” шигырендә суфичылык әдәбиятына хас нинди үзенчәлекләр чагылыш таба? (10 балл)

III. Иҗади эш. (15 балл)

Соңгы елларда киң кулланылышта булган *компьютер, ноутбук, телефон, планшет, телевизор* турында 5 әйтем уйлап чыгарып языгыз.